ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2025 Мөслим авылы № 17

**Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында**

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балансклы тукландыру нормаларын үтәүне тәэмин итү, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Федераль законның 37 маддәсен үтәү максатыннан, Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 213н номерлы боерыгы, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 11 мартындагы 178 номерлы боерыгы нигезендә «Белем бирү учреждениеләрендә укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне туклндыруны оештыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2024елның 12 сентябрендәге 777 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024елның 16 сентябрендәге 789 номерлы карары белән, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1.1. Гомуми белем бирү оешмаларының урта, төп һәм башлангыч гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә
«Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Михайловка урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Мөслим гимназиясе» МБГББУ
«Г.Тукай исемендәге Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
Мөслим лицее МБГББУ
«Тат. Буләр урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Әмәкәй төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Баек төп белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Олы Чакмак төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«М.Бүләр төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Түбән табын төп гомуми белем бирү мәктәбе»МБГББУ
«Яңа Усы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Рус Шуган төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Салауз-Мухан төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ

«Тат.Шуран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Тойгелде төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Мәлләтамак башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Метрәй башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
бер тапкыр кайнар туклану (кайнар иртәнге аш) оештырырга.

2. Барлык муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 класс укучылары көнендә 69,43 сум (алтмыш тугыз сум 43 тиен) күләмендәге бушлай кайнар иртәнге аш белән тәэмин итәргә.

3. Ата-аналар (законлы вәкилләр) белдерүе буенча, ГПДда (озайтылган көн төркемнәрендә) шөгыльләнүче һәм күрше авыллардан база мәктәпләрендә укучыларга 20,00 сум (егерме сум 00 тиен) өстәмә туклану оештырырга.

4. Урта, төп гомуми белем бирү оешмалары көненә бер укучыга 5-11 сыйныф укучылары өчен кайнар иртәнге аш бәясен 69,43 сум (алтмыш тугыз сум 43 тиен) күләмендә билгеләргә, шулардан 9,60 сум (тугыз сум 60 тиен) субсидия;

4.1. Белем бирү оешмасында туклануны оештыру һәм түләү процессы белән бәйле операцияләрне исәпкә алу өчен AVSU.RU (AVSU.RU системасы) - ЭВМ өчен үзәк программасы һәм мәгълүматлар базасы.

5. «ТР Мөслим муниципаль районының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Л.Я. Хәбибуллинага:

5.1. Укучыларның кайнар туклануын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны максатчан куллануны тәэмин итәргә;

5.2. Витаминнар һәм микроэлементлар белән баетылган төп туклыклы матдәләр күләме буенча балансланган өстәмә туклану һәм кайнар иртәнге аш нормаларының һәм сыйфатының үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә;

5.3. Гомуми белем бирү оешмаларына продуктларның өзлексез китерелүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

6. Укучыларны кайнар тукландыруны оештыручы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

6.1. Мәктәп ашханәләрен азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә.

6.2. Санитар нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында кайнар туклануга производство контролен үткәрү.

6.3. Ике тапкыр туклану мөмкинлеге булмаса, туклануның югарыда күрсәтелгән бәясе нигезендә акчалата компенсация бирүне оештырырга.

7. 5-11 сыйныф укучыларының кайнар иртәнге ашлары өчен түләүдән түбәндәге категорияләрдәге укучыларны азат итәргә:

- дүрт һәм аннан да күбрәк балалы күп балалы гаиләләрдән укучылар;
-ата-аналары полиция хезмәткәрләре булган укучылар;
-ата-аналары 1, 2 төркем инвалид булган укучылар.

7.1. Түбәндәге укучыларны ашату өчен түләүдән азат итәргә:

-инвалид балалар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар.

8. Урта гомуми белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныф укучыларын түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итәргә; Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының төп һәм башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән, РФ Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, РФ Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби

хезмәткәрләр һәм затлар, «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар гаиләләре арасыннан 1-9 сыйныф укучыларын түләүсез кайнар ашату белән, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән РФ Федераль куркынычсызлык хезмәтенең ТР буенча идарәсе, шулай ук гражданинның хәрби хезмәт үтү чорына махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категория гражданнарның гаиләләреннән балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итәргә.

8.1. Күрсәтелгән ташламаны гомуми белем бирү оешмасы укучысының ата-анасын (законлы вәкилен) хәрби комиссариатның чакыру турындагы белешмәсе нигезендә бирергә.

9. Мөслим муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУ (Бубекова Н.А.га) гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку чорында туклануны оештыруга бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

10. «Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 13 июнендәге 276 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

11. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм ТР Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга

12. Әлеге карар «09» гыйнвар 2025 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

13. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М. Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Салихҗанов**